**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

«10» апрель 2024 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 10 апрелендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының 07.11.2023 карарының 1нче номерлы Киекле авыл җирлеге Кизләү торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында элек расланган карарга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кизләү авыл җирлегенең 07.11.2023 карарының 2нче номерлы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә ризалык бирәсезме?:

Югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган 2024 елда 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылында яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә алынган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән эшләр исемлеген түбәндәге редакциядә бирергә:

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Кизләү торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, шул исәптән таш, суккан кирпеч, туфрак, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу, ташу, салу), чокыр ремонтлау (коелган асфальт);

- Кизләү торак пунктында урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) төзү, сатып алу;

- Кизләү торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- Кизләү торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү;

- Кизләү торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 373 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 221 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 196 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 25 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының 07.11.2023 карарының 1нче номерлы Киекле авыл җирлеге Кизләү торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында элек расланган карарга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кизләү авыл җирлегенең 07.11.2023 карарының 2нче номерлы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә ризалык бирәсезме?:

Югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган 2024 елда 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылында яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә алынган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән эшләр исемлеген түбәндәге редакциядә бирергә:

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Кизләү торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту, шул исәптән таш, суккан кирпеч, туфрак, вак таш, ком, асфальт ватыклары (сатып алу, ташу, салу), чокыр ремонтлау (коелган асфальт);

- Кизләү торак пунктында урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) төзү, сатып алу;

- Кизләү торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- Кизләү торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү;

- Кизләү торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау, товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат

муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Л.И. Кашапова

Киекле авыл җирлеге башлыгы: Л.И. Кашапова